| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЯР БУЕ МОРКВАШЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.11.2020 с. Набережные Моркваши № 11

Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркварашы авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004нче елның 24нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2020нче елның 31нче октябрендәге 1нче, 7нче ноябрендәге 3нче, 2020нче елның 14нче ноябрендәге 4нче, 2020нче елның 14нче ноябрендәге 5нче номерлы гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны тормышка ашыру максатларында Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр Буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ___________И Х. Гаязов

Яр буе Морквашы авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020нче елның 16нчы ноябреннән
11нче номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегендә
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Бу Тәртип Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Кагыйдәләрен билгели

2. Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнар җыеннарында катнашуларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, үзара салым акчаларын түләү 2021нче елның 1нче гыйнварыннан 2021 елның 31нче октябренә кадәр башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;

б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.

4. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 1нче төркем инвалидлар,

б) күп балалы гаиләләр,

в) көндезге уку йортлары студентлары,

г) Бөек Ватан сугышы ветераннары

түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша почтадан акча күчерү белән (исәп-хисап оешмалары) тормышка ашырыла, яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталының https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек - ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.